**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 30 июлендәге 3169 номерлы карары**

**Авиация көненә багышлап, ел саен уздырыла торган**
**«Мин күкне сайлыйм» бәйрәменә әзерлек һәм аны уздыру чорында**
**Казан шәһәренең автомобиль юлларында транспорт чаралары**
**хәрәкәтен чикләү турында**

Авиация көненә багышлап, ел саен уздырыла торган «Мин күкне сайлыйм» бәйрәмен оештыру максатыннан, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 18 апрелендәге 353 номерлы «Рәсми спорт ярышлары уздырганда иминлекне тәэмин итү кагыйдәләрен раслау турында»гы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк яки муниципальара, җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү яисә туктату тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә:

**1. Карар бирәм:**

1.1. әлеге карарның кушымтасы нигезендә 2024 елның 3 августында 14.00 дән алып 22.00 гә кадәр автомобиль юллары буйлап, «Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе» муниципаль бюджет учреждениесе билгели торган форма буенча махсус рөхсәтнамә белән җиһазландырылган транспорт чараларыннан тыш, транспорт чаралары хәрәкәтен чикләүне кертергә;

1.1.1. Декабристлар урамы киселешеннән алып Әпсәләмов урамы киселешенә кадәрге участокта Сибгат Хәким урамы буенча ике якка;

1.1.2. Сибгат Хәким урамындагы 3 номерлы торак йорттан алып Сибгат Хәким урамына тоташкан участокта Бондаренко урамы буенча ике якка;

1.2. «Казан» гаилә үзәгенең күзәтү мәйданчыгына керү мөмкинлеген чикләргә;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.3.1. транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турындагы мәгълүматны «Татарстан Республикасы рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырырга;

1.3.2. хәрәкәтне вакытлыча чикләү чорында юл билгеләрен урнаштыруны юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары дислокациясе (кушымта итеп бирелә) схемасы нигезендә башкарырга;

1.4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (И.И.Сәлахетдинов) Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләре белән берлектә (Р.Х.Шәмсетдинов, В.В.Жаворонков), кушымта итеп бирелгән юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары дислокациясе схемасына нигезләнеп, хәрәкәтне вакытлыча чикләү чорында таранга каршы техника чыгаруны тәэмин итәргә;

1.5. «Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе» муниципаль бюджет учреждениесенә (А.Ф.Латыйпова) әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән рөхсәтнамә үрнәкләрен Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе бүлегенә тапшырырга;

1.6. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**2. Тәкъдим итәм:**

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Н.Д.Закиров) җәмәгать тәртибен саклауны оештырырга, әлеге карар нигезендә Казан шәһәрендәге урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участокларында юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-җайга салу гамәлләренең үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итәргә;


2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә (В.А.Казанцев) Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участокларында транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим.**

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 30 июлендәге
3169 номерлы карарына
кушымта

**Юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары дислокациясе схемасы**




---